Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең Сәрдегән авылында

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«24» март, 2024 ел. №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 нче маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең Сәрдегән торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. 2023 елның 10 ноябрендә Татарстан Республикасының Балтач муниципаль районының Салавыч авыл җирлегенең Сәрдегән торак пунктында гражданнар җыелышы №2 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 нче пункт түбәндәгечә расларга:

«2. Алынган акчаны түбәндәге эшне башкарып җирле әһәмияттәге проблемаларны чишү өчен кулланырга:

- торак пункт территориясен төзекләндерү: "Газинур аланлыгы" га капка урнаштыру; территорияләрне чистарту һәм җыештыру.

- һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү: Сардыган авылында Бөек Ватан сугышы ветераннары өчен һәйкәл булдыру;

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту: Сәрдыган авылына юлны ремонтлау;.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Салавыч авыл җирлеге башлыгы Р.К.Латипов